СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.09.2018 ел с.Ямбулатово № 47 – 199

**Ямбулат авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы, «Ямбулат авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Ямбулат авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге 46-196 номерлы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 20 сентябрендәге 131-ФЗ номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Ямбулат авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчаларны җибәрергә риза булырсызмы:

- Ямбулат авылындагы зират территориясендә инвентарьга бина төзү.

ӘЙЕ ЮК

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н.Ахметзянов